ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан ирекe турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның $1^1$ пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйләнеше булган оешмаларның һәм физик затларның БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яисә БМО Иминлек Советы карарлары нигезендә махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган исемлекләренә кертелгән зат.»;

2) 11 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйләнеше булган оешмаларның һәм физик затларның БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яисә БМО Иминлек Советы карарлары нигезендә махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган исемлекләренә кертелгән зат.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 04 октябрь
№ 61-ТРЗ